| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИЖ-БОБЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЖ-БУБЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.01.2023 Иж-Бубый авылы № 02

2023 елга вафат булганнарны күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр күрсәтүнең исемлеге бәясен раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, "Җирләү һәм күмү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, "Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында" Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.01.2023 елның ЛХ-28/269/2023 номерлы "җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге бәясе турында" хатын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны(ире), законлы вәкиле булган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2023 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны(ире), законлы вәкиле булмаган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2023 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

3. Әлеге карар 01.02.2023 елдан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Р. Р. Ваhапов

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Иж-Бубый авыл
җирлеге Башкарма комитетының
24.01.2023 елның 2 номерлы
карарына  1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны(ире), законлы вәкиле булган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2023 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| Т/с | Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3337,43 |
| 3. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 819,12 |
| 4. | Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 3636,93 |
| | **Барлыгы** | **7793,48** |

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Иж-Бубый авыл
җирлеге Башкарма комитетының
24.01.2023 елның 2 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны(ире), законлы вәкиле булмаган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2023 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| Т/с | Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Тәнне төрү | 600,27 |
| 3. | Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3007,84 |
| 4. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 737,87 |
| 5. | Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 3447,50 |
| | **Барлыгы** | **7793,48** |